СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОКУВАКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ КУАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 1 июне Иске Куак № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 октябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 6 апрелендәге «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 608 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 октябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1 статьяның егерме бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорт дип Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина таныла».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н Сушкова